РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 156

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 11нче апрелендәге 29нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазифаларга дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар җиткерүе, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазифалар биләүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар җиткерүе турында» Карарына үзгәрешләр кертү турында

2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 11нче апрелендәге 29нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазифаларга дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар җиткерүе, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазифалар биләүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар җиткерүе турында» Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка таратылганнан соң) көченә керә һәм 2016нчы елның 1 гыйнварыннан соңгы хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин